

# ГӘРӘБӘ

**Әдәби берләшмә газетасы**

№ 5

Рухи яктан үстерүче - туган тел,

һәр милләтнең бердәнбере булган тел.

Татар барда яшәр әле минем тел!

Ышана бит, инана бит күңел гел.




**Рубрикалар:**

- ***Кызыклы вакыйга***
- ***Бөек шәхес***
- ***Студент тормышы***
- ***Иҗат***
- ***Халык иҗаты***
- ***Җырлыйк әле***

## Бөек Ватан сугышы



Сугыш...

Бер карасаң, биш хәрефле гади бер сүз, әмма ул сүз эчендә миллионлаган кеше жаны, күз яше һәм никадәр кайгы. Без беләбез: сугыш – ул начар, кайгы төсмеренә ия төшенчә, ләкин ни дәрәҗәдә икәнен күз алдына да китерә алмыйбыз. Сугыш - ул гүя аждаһа: бар нәрсәне яндыра, жир йөзеннән юкка чыгара, бар дөньяны тетрәндерә, меңләгән, миллионлаган кеше гомерен үзенә тартып ала...

Дәвамы 2 нче биттә →



Дәвамы

## Бөек Ватан сугышы...

Сугыш... Ике иҗекле гади, ләкин дүрт елны үз эченә алган сүз. Дүрт ел күп тә түгел шикелле, әмма ул салган тирән яралар, кайгы-хәсрәтләр бик озак елларга кадәр сакланыр әле.

Менә 72 ел рәттән илебез Җиңү көнен бәйрәм итә, 72 ел рәттән яралар кабат яңара.

Ярты гасырдан артык Россия һәм Татарстанның барлык халкы яу кырында башларын салып калган ата-бабаларыбызны искә ала. Күбебез сугыш батырларын үз күзебез белән күрмәсәк дә, алар белән горурланабыз, рәхмәт әйтеп, баш иябез.

Хәзерге вакытта Җиңү көне аеруча олылап үткәрелә. Шушы бөек бәйрәмне уздыруда бик күп оешмалар көч куя. Төрле концерт программалары, салютлар, митинглар бәйрәмгә масштаблырак, тантаналырак төсмер бирәләр, аны тагын да ямьлиләр. Соңгы берничә ел эчендә 9 нчы майда Гомумроссия һәм Татарстан буенча “Үлемсез полк” маршы “атлый”. Шушы чарада катнашучыларның саны елдан-ел артуы күңелне сөендерә.

Безгә дә, Казан педагогия көллияте студентларына да, быел “Үлемсез полк” маршында катнашу бәхете елмайды. Алдагы елларда телевизордан гына карап утырсак, быел үзебезнең ветеран бабаларыбыз фотографиясен тотып, маршта катнаштык. Күңелдә каршылыклы хисләр ташкыны: бер яктан, илебез һәм батыр бабаларыбыз өчен горурлык, икенче яктан, күпме гомерләрне корбан иткән сугышка нәфрәт. Әйтерсең, маршта без түгел, ә бабаларыбыз үзләре атлый. Әйтерсең, 18 яше тулар-тулмас гаярь егетләр кире кайтып, Җиңү маршында үзләре катнаша.

Марш тәмамлануга, бәйрәмне тагын да тулыландырап, патриотик рухтагы җырлар яңгырады. Кичен казанлыларга матур салют күрергә насыйп булды.

9 нчы май елга бер генә килсә дә, без үз батырларыбызны һәрвакыт искә төшереп торсак иде. Җир йөзеннән китkәннәрнең каберләренә эзне суытмасак иде. Сугыш кырларында югалганнарның исемнәрен кайтаруда үзебездән өлеш кертсәк иде. Исәннәренә кадер-хөрмәтебезне җәлләмичә, ярдәмебездән ташламыйча, санаулы көннәрен тынычлыкта, бәхеттә үткәрергә ярдәм итсәк иде. Без, киләчәк буын вәкилләре, бүгенге тыныч көннәребез өчен үзләрен корбан китергән әби-бабаларыбызның ышанычын акласак иде.

*Гибадуллина Миләүшә ,212 төркем*

# “Яхшылык атнасы”

**Кызыклы вакыйгалар**

Яшәү безгә авыр булыр иде
Яхшылыктан башка.
Шуңа күрә яхшылыкны эшлик
Без үзебез башта.

*Р.Миңнуллин*



Яхшылык - ул бер-береңә ярдәмгә килергә әзер булу, якын кешең өчен үзеңне корбанга китерүдер, мөгаен. Яхшылык беркайчан да онытылмый. Хәзерге вакытта күп кешеләрнең уйлары, эшләре белән акча идарә итә. Шуның өчен, дәүләтебез бөтен мөмкинлекләрне кулланып, яхшылык кылуга өнди.

Казан педагогика көллияте инде гадәткә кергән Бөтенроссия акциясенә актив кушылды. Аның максаты - республикада яшәүчеләрне, беренче чиратта яшьләрне, иректә эшчәнлеккә тарту. Язгы “Яхшы эшләр” атналыгы кысаларында күп кенә җәмгыятькә файдалы чаралар һәм акцияләр планлаштырылды: шимбә өмәләре, өлкән һәм ялгыз кешеләргә ярдәм итү, экологик акцияләрдә катнашу һәм башкалар. Безнең студентлар атна дәвамында балалар йортларына, ярдәмгә мохтаж гаиләләргә материаль ярдәм күрсәттеләр. Адым саен яхшылык кылу - безнең бурыч. Бу сыйфат күңелдә балачактан ук тәрбияләнеп, гомер буена узенең мәгънәсен югалтмаска тиеш.

*Фәтхуллина Ландыш,212 нче төркем*





**Тәрәбә**

## *Июнь — чәчәкләр ае*

Җәйдән дә матуррак чак бар микән?!
Бөтен жир яшеллеккә күмелә.

Узган җәйне мин Балык бистәсе районында үткәрдем. Бу район Кама елгасында урнашкан.

Июнь — чәчәкләр ае. Шушы айда болын-кырлар гына түгел, юкәләр дә чәчәккә күмелә. Бу айда бал кортлары армый-талмый эшлиләр, бал җыеп калырга тырышалар. Июньдә кешеләр дару үләннәре җыялар. Чөнки күп кенә дарулар чәчәкләрдән ясала. Балык бистәсе районында чәчәкләрнең ниндиләре генә юк! Беркөнне без дә - әбием һәм мин - урманга дару үләннәре җыярга киттек. Әйләнә-тирәдәге матурлыкка сокланып, әбием күрсәткән дару үләннәрен җыя торгач, шактый ардырды. Без чишмә буенда ял итәргә туктадык. Бит-кулларыбызны юып, чишмәнең саф суын эчкәч, арыганнар онытылды. Дару үләннәре җыюыбызга шатланышып, өйгә кайттык.

Июнь ахырында җиләкләр дә өлгерә башлый. Мин каен җиләге җыярга яратам. Моңдагы урманнар җиләккә бик бай. Каен урманында кошлар җырын тыңлый-тыңлый, иртәнге чыклы үләннәр арасыннан кызарып пешкән җиләк җыюдан да рәхәт мизгел бар микән?! Савытың тулгач, аның хуш исенә исереп, матурлыгына сокланып бер мәл карап торасың. Ә җиләк сине һаман җибәрми. Үлән арасында җемелдәп, кызыктырып тора. Аның тәме... Бернинди экзотик җимешләр дә алыштыра алмый безнең урманнарда пешкән каен җиләгенең тәмен!

Җәй үтте дә китте. Минем әбиләрдән китәсем дә килмәде. Ләкин укырга кирәк. Каникулларда көч җыеп, ял итеп, шактый үсеп, мин Казан педагогия көллиятенә белем алырга кердем. Инде бүгеннән мин киләсе җәйне сагына да башладым. Тизрәк җәй җитсен инде!

*Шигапова Алия, 911 төркем*



Бөек шәхес

# Закир Рәмиев (Дәрдемәнд)

**Гасырлар кичте китте,китте еллар!**

Шагыйрьнең дөньяви исеме - Закир Рәмиев. “Дәрдемәнд”, ягъни “хәсрәт кичерүче” тәхәллүсен алып, ул әдәбиятта үзен фәлсәфәче, “моңлы җан” буларак билгеле. Аның иҗатында төп темаларның берсе – милләт язмышы.

Дәрдемәнд шәхес буларак та, иҗатчы буларак та тиешенчә өйрәнелмәгән. Дәрдемәнд үзенә бертөрле шагыйрь. Ул нигездә зыялы кешеләр өчен язган. Теләсә кем аны аңлап, иҗатыннан ләззәт ала алмаска да мөмкин. Аны тыңлар өчен шактый әзерлекле булырга кирәк.Шагыйрьнең биографиясендә дә каршылыклар бар. Билгеле булганча, Закир Рәмиев инкыйлабны кабул итми, шулай да бар булган мөлкәтен яңа хакимияткә тапшырып, туган илендә кала. Рәсми рәвештә ул салкын тиюдән вафат була дип санала, гәрчә Закир Рәмиевнең ачлыктан вафат булуы чынбарлыкка күбрәк туры килә.

Әлбәттә, үлеме алдыннан аның матди хәле авыр була. Ул еллар, гомумән, авыр була. Әдәбият галимнәре Закир Рәмиевнең бик укымышлы кеше булуын яза. Ул Орск өязендә мәдрәсә тәмамлагач, Төркиянең Истанбул шәһәрендә белем алган. Туган теленнән кала, төрек, гарәп, фарсы, рус телләрендә иркен аралашкан.

Нәширлек эшенә мөккибән булган Закир чит мәмләкәттән абыйсы Шакирга төрек басма матбугатын да җибәреп тора. Шакир Рәмиевнең энесенә язган хатыннан күренгәнчә, аларның типография ачу омтылышлары да булган.

Төркиядән кайткач, Дәрдмәнд газеты ачарга талпынып карый, тик патша режимы бу вакытта татарларга матбугат ачуны тыйган. Ләкин тора-бара ул теләгенә ирешә, аның нәширлегендә Оренбургта “Вакыт” һәм “Шура” журналлары басыла. “Рәмиевләр татар матбугатын аякка бастыру өчен шактый күп көч куйганнар. Аларның “Вакыт” һәм “Шура” журналлары озак вакытлар чыгып килгән.

# “Мин татарча сөйләшәм...”

**Студент тормышы**



22 апрель көнне Казанның Бауман урамында “Татар-дозор 2017” квест-уены үтте. Чараның максаты — социаль-актив яшьләрдә милли мәдәниятне һәм туган телне саклауда җаваплылык хисе тәрбияләү. Быел квест тугызынчы тапкыр үткәрелде. Һава торышының сүрән, яңгырлы булуы командаларга квест үтәргә бер дә комачау итмәде.

Казан педагогия көллиятеннән уенда 3 төркем катнашты. "Татар дозор" уены, Тәбрис Яруллинның командаларга уңышлар теләп, эчендә беренче бирем булган конвертлар өләшүе белән башланып китте. Барлыгы 60 этап иде. Алар төрле нокталарга барып, төрле сынауларны үттеләр.Шулар арасында Фукс йорты, Г.Камал театры, “Шәрык” клубы нокталары бар иде. Катнашучылар тәрҗемәче, реклама бирүче, режиссер булып та, Казан халкы белән татарча биеп, җырлап, Дәрдемәнд турында фикерләр алышып та алдылар.Төркемнәр берәр биремне үтәп, шунда ук аны чын татар телендә “WhatsApp”ка диспетчерга, ә оештыручылар җавап хатында алдагы биремнәрне язып җибәрә бардылар.

Җиңүчеләр 26 апрель көнне Бауман урамында “Мин татарча сөйләшәм” акциясендә билгеле булды.

Минемчә, “Татар дозор”да катнашучы укучылар, студентлар бу уенда күп эмоцияләр алдылар, яңа дуслар таптылар, татар телен саклау һәм аның киләчәге безнең кулда икәнлегенә инандылар.

*Асадуллина Алсу, 212 төркем*



# Хикәяләр

Иҗат

**“Мәк чәчәге” нәсере**

*(өзекләр)*

Тирән бомба чокырында ялгыз мәк чәчәге үсеп утыра. Аның тирәсендә коры ком гына өелеп тора. Чокырдан югары тирә-юньдә нииләр үскәнен, юлдан кемнәр үткәнен мәк чәчге күрми. Аның янына бизәкле канатлы күбәләкләр генә очып киләләр. Аңа кунып назлап, иркәләп, китәләр. Ләкин бу сирәк була. Мәк чәчәге көннәр буе берүзе. Бу урында элек кечкенә дача-авыл булган. Анда мәк чәчәкләре, гөлчәчәкләр, сиреньнәр, алмагачлар үскән. Дошман әлеге урынга бомба ташлаган. Күз ачып йомганчы дача-авыл җимерелгән. Ләкин дошман чәчәкләрнең нәселен корыта алмаган. Ялгыз мәк чәчәге комлы чокыр төбендә матур булып үсеп киткән. Узгынчы солдат, чокыр төбенә төшеп, шул чәчәккә сокланып карый. Бу авыр сугыш вакытында да солдат чәчәк яныннан тыныч кына узып китә алмый. Матурлыкка сокланып баш ия.

***

Бу хәл сугыш вакытында була. Лейтенант Ивановның ротасы урман эченнән атлый. Зариф содат үзенең авылы, хатыны, баласы турында уйлап бара. Һавада самолет күренә. Сугышчылар агачлар арасына яшерәнәләр. Зариф үзеннә ерак түгел өч-дүрт яшьлек кыз баланы күрә. Кечкенә кыз бик күп елаган. Аның битләрендә яшь эзләре бар. Зариф бу баланың адашканын аңлый. Баланы күтәреп ала, аңа шикәр бирә. Бу кызчык аңа бик тиз ияләшә. Үзенең әти-әнисе, кәҗә бәтиләре турында сөйли. Зариф аптырап кала, чөнки баланы ут эченә алып барып булмый. Шуңа күрә ул тиз генә станциягә таба китә. Станциядә эшелон тора. Кешеләр вагоннарга утыралар. Кинәт бер рус хатыны: “Балам!” – дип кычкырып, алар янына чабып килә. Бу кызын югалткан ана була. Зариф тимер юл буйлап йөгереп китә. Үзенең ротасын куып җиткәч, лейтенантка кайда булуын сөйләп бирә. “Сез бик зур изгелек эшләгәнсез. Бик зур рәхмәт сезгә”, - ди лейтенант.

*(А.Еники)*

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*

## Шигырьләр

**Иҗат**





### Тургай

Бер тургай һәр таң саен
Жыр суза өзеп-өзеп.
Бу жырны шатлыгыннан
Жырлыйдыр тезеп-тезеп.

Яз кошы зур кырларда
Сайрыйдыр күккә менеп.
Чәчү чәчкән егетләргә
Көч биреп, куәт биреп.

Сайрагыз, яз кошлары,
Дөньялар тыныч булсын!
Яз жылысы, тургай моңы
Болыннарга таралсын.

*Заһретдинова Люция, 311 төркем*

### Әбигә

Синең туган көнеңне
Без гел көтеп алабыз.
Ямьле көлүләреңне,
Көн дә күреп торабыз.

Назлы кулларың белән
Бишекләрдә биләдең,
Төннәрен йокламыйча,
Әкиятләр сөйләдең.

Синең назлы сүзләрең,
Безгә моң булып тора.
Безгә кылган догалар
Гел өмет биреп тора.

Сиңа озын гомерләр
Без һәрвакыт телибез,
Елмаюың күрергә
Өметләнеп яшибез.

Йөзең белән картайсаң –
Күңелеңдә картайма.
Безне сөеп үстерден:
Һич тә сине онытмам!

*Тимофеева Регина, 911 төркем*

# Шигырьләр

Иҗат

## Рәхмәт

Ал нурларын сузып таңнар ата:
Әтәч торган , азан әйтелгән.
И авылым,синең матурлыкка
Юктыр каен, башын имәгән.

Жылы җилләр яфрак калкыта,
Чәчәк ата олы юкәләр.
Шуңа күрә сөйгән авылыма
Бүләк итәм язып  шигырьләр.

Туган авыл миңа илһам бирде,
Иман бирде әти-әнием.
Бүләк итте миңа киң болыннар
Матурлыкны күрә белүне.

Рәхмәт әйтәм горур агачларга.
Чишмәләргә ,моңлы кошларга.
Туган илем, сиңа рәхмәт әйтәм:
Тыныч төнгә ,алсу таңнарга.

*Нуртдинова Рузилә, 3 курс*

## Язмышым

Мин кыз бала – өзелмәгән
чәчәк:
Кайчан өзелүем билгесез.
Өзелгәч, чәчәклрдән алма
күк,
Калмам микән димен,
җимешсез.

Мин кыз бала– минем бар да
алда.
Килә минем җимеш бирәсем.
Сабыйларым туып, аларны бит
Сөеп-сөеп килә үстерәсем.

*Шәйхиева Альбина, 2 курс*

***

Гашыйк булдым мин сиңа,
Кышның матур көнендә.
Көннәрне, төннәрне
Сихри мәлгә күмгәндә.
Янды күзләр сөюдән,
Беренче кат күргәндә.
Назландым кочагыңда
Хисләреңә төргәндә...
*Шакирова Алинә, 921 төркем*

# Әкияттә Кунакта

Халык иҗаты



## Ай белән Кояш

Ай белән Кояш элек заманда гел бер җирдә генә тормакчы булганнар. Шуннан соң, бөтен кошларны җыеп, шул турыда җыелыш ясаганнар. Бөтен кошлар, боларның бер җирдә торуларына риза булып, шуңа кул куйганнар.

Болар арасында бары бер генә кош кул куймыйча калган, ди. Ул булган Ярканат. Бүтән кошлар Ярканаттан сораганнар:
— Бөтен кошлар кул куйганда, нилектән син генә кул куймадың? — дигәннәр.
— Кулны мин,— дигән Ярканат,— шул сәбәпле куймадым,— дигән:
— Кояш белән Ай бер җирдә генә торсалар, җил бер генә яктан исәр, агачлар кәкре булып үсәрләр, игеннәр дә Кояш төшкән җирдә генә үсәр. Кояш төшмәгән җирдә үсмәс,— дигән.

Шуннан соң бүтән кошлар әйткәннәр:

— Дөрес әйтә шул, Кояш төшмәгән җирдә иген үсми инде ул,— дигәннәр.
Ай белән Кояшка икесенә дә, бер җирдә тормаска, әйләнеп йөрергә, дип карар чыгарганнар, ди.

Шуннан соң Кояш әйткән Ярканатка:

— Мин сине үземнең яктылыгымда йөртмәм,— дигән. Шунлыктан Ярканат көн яктысына чыгып йөри алмый икән. Аңа Ай сүз әйтмәгән, шуңа күрә ул Ай яктысында бик әйбәт йөри, ди. Ай белән Кояшның болай әйләнеп йөрүен бөтен кош-кортлар, бөтен халыклар бик дөрес дип кабул иткәннәр, ди. Шуннан соң игеннәр дә яхшы уңа башлаган, ди.

# Мәкальләр

Халык иҗаты

*Ак булмаса да, пакь булсын.*

*Аккан су кире кайтмас.*
*Аткан ук кире кайтмас.*

*Акыллы дошманнан курыкма,*
*Ахмак дустан курык.*

*Илдә йөргән ил таныр,*
*Кырда йөргән җир таныр.*

*Җир-суы бар җирен сөйләр,*
*Ил-йорты бар илен сөйләр,*
*Ил-йорты юк ниен сөйләр?*


*Сыерчык, диңгез артына китсә дә,*
*Үз туган оясына кайта.*

*Һәр гөл үз сабагында чәчәк атар.*

*Оясыз сандугач сайрамый.*

*Болгар йорты – Идел йорт,*
*Идел эче –имин йорт.*







# Ж□□□□□□ ә□□

## Солдатлар

Озатып вокзаллар каршында,
Маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
Дөньяны күрмәгән балалар

Балалар керделәр утларга,
Балалар сүз бирде тупларга.
Күпләре, төренеп шинельгә,
Калдылар еракта йокларга.

«Балалар, торыгыз, балалар,
Ашыгыз суына табында...»
Ничә ел тормыйлар балалар
Иделдә һәм Дунай ярында...

Уятма, йокласын, син, ана,
Айларны, елларны санап бар:
Күңелдә һаман яшь, гел бала -
Кайтмаган солдатлар,
солдатлар

Ана ул йокламый, сабые
Юрганын ачса да уяна.
Аналар йөрәге шикелле
Мәйданда мәңгелек ут яна.

Аналар йөрәге шикелле
Ут яна, уйлана, талпына.
Аналар хәтере шикелле
Җил йөри курганнар артында





*Әдәби консультант:* *“ГӘРӘБӘ” әдәби берләшмәсе җитәкчесе Нуриева Лилия Фаил кызы*

*Баш мөхәррир:Мәрдәнова Айгөл*

*Редколлегия: “ГӘРӘБӘ” әдәби берләшмәсе әгъзалары*